**СОВЕТ КУТЕМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Клубная, д.1а, село Кутема, 423112

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**КҮТӘМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
Клуб урамы, 1а йорты, Күтәмә авылы, 423112

тел.+7(84396) 4-30-88, e-mail: Kut.Cmn2@tatar.ru

---

**№ 103** **18 декабрь 2023 ел**

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Күтәмә авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Күтәмә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге Советының 2023 елның 29 июнендәге №87 карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законнарга, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 2 ноябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына таянып, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Күтәмә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге Советының 2023 елның 29 июнендәге № 87 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 4.13 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «4.13. Класс чины бирү көне дип класс чины бирү турында карар кабул ителгән көн санала».

1.2. 4.19 пунктны төшереп калдырырга.

1.3. 4.21 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «Муниципаль хезмәткәргә класс чины бирү турында карар, Нигезләмәнең 4.15 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, класс чинын бирү турында барлык кирәкле документлар белән

органга яки җирле үзидарәнең класс чинын бирергә вәкаләтле вазыйфаи затына тапшыру турында тәкъдим кертелгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш».

2. Әлеге карарны рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге башлыгы урынбасарына, Совет рәисе урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Күтәмә авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе Н.Г. Сабиров